# Унсигезенче декабрь.

Сыйныф эше.

Фигыль төркемчәләрен гомумиләштерепкабатлау.

# Сүзлек эше

Эхлаксызлык – тәртипсезлек

Гайбәт – ялган сүз

# Белемнәрне тикшерү

1.Фигыль нәрсәне белдерә?

А)Эшне, хәлне, хәрәкәтне ә)предметның билгесен б)предметның санын.

2.Фигыльнең ничә төркемчәсе бар?

А) 10 ә) 7 б) 2

3.Затланышлы фигыльләргә керә

А)исем фигыль ә) инфинитив б)хикәя фигыль

4.-са, -сә белән нинди фигыль ясала?

А)сыйфат ә)шарт б)хәл

5.Сыйфат фигыль җөмләдә нинди кисәк булып килә?

А) ия ә) тәмамлык б) аергыч

6.Хәл фигыльнең ничә төре бар? Кушымчаларын күрсәт.

А) 3 ә) 4 б) 5

7.Нинди ике фигыль заман белән төрләнә?

1.Фигыль нәрсәне белдерә?

А)Эшне, хәлне, хәрәкәтне ә)предметның билгесен б)предметның санын.

2.Фигыльнең ничә төркемчәсе бар?

А) 10 ә) 7 б) 2

3.Затланышлы фигыльләргә керә

А)исем фигыль ә) инфинитив б)хикәя фигыль

4.-са, -сә белән нинди фигыль ясала?

А)сыйфат ә)шарт б)хәл

5.Сыйфат фигыль җөмләдә нинди кисәк булып килә?

А) ия ә) тәмамлык б) аергыч

6.Хәл фигыльнең ничә төре бар? Кушымчаларын күрсәт.

А) 3 ә) 4 б) 5

7.Нинди ике фигыль заман белән төрләнә?

## Ялганчының өе янган – берәү дә ышанмаган

Бер тапкыр алдасаң, ышанычыңны югалтасың. Ялган сөйләгән кешегә ” Алдакчы” дигән бик ямьсез кушамат тагалар. Алдакчының дөрес сүзенә дә ышанмыйлар, аңа бер эшне дә ышанып тапшырмыйлар.

# Вәгъдәндә тору

Вәгъдә - әйткән сүзеңне, эшләргә тиеш эшеңне үз вакытында үтәү. Вәгъдәңне үтәү, вәгъдәндә тору – шулай ук кешенең күркәм сыйфатларыннан берсе!

Әйткән сүз – аткан ук. Әйттеңме, аны үтәргә кирәк. Биргән вәгъдәңне үтәмәү-

иң зур тәртипсезлек


# Гайбәт сөйләү – начар гадәт.

Кешене начар итеп күрсәтергә тырышып, аның турында ялган яки кечкенә җитешсезлекне күпертеп сөйләү – гайбәт дип атала.

Кеше турында гайбәт сөйләү - әдәпсезлек, әхлаксызлык.

Гайбәт сөйләүдән сак булыгыз!

Бик күп яздым,
Бераз арыдым,
Бармак һәм кулым талды.



## Ял итү минуты

**Бик күп яздым,
Бераз арыдым,
Бармак һәм кулым талды.
Бармакларны селкетәм,
Иңбашларын сикертәм.
Уңга, сулга карадым,
Аска, өскә карадым –
Тагын яза башладым.**

# Олылар сүзе.

Калган эшкә кар ява.

Белем – нур, белмәү – хур.

Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

Алтының белән мактанма, акылың белән мактан.

Эш сөйгәнне ил сөяр.

# ӘДӘП-ӘХЛАК.



# Яхшылык эшлик

Яшәү безгә авыр булыр иде
Яхшылыктан башка.
Шуңа күрә яхшылыкны эшлик
Без үзебез башта.
Тормыйк көтеп яхшылыкны безгә
Эшләр диеп кемдер.
Яхшылыклар эшлик! Күңелем, син дә
Үз-үзеңне күндер!
Барыбыз да яхшылыкка мохтаҗ,
Бу заманда бигрәк.
Яхшылыкны эшләү җиңел түгел,
Ә эшләргә кирәк!

# Тырыш балалар.



Яхшы булыр балалар
Сабакка күз салалар.
Тик тору начар эш дип,
Иртәрәк кузгалалар.

Таза булыр өс-башы,
Китап булыр юлдашы,
Сабак укып туктагач,
Вакытында булыр ашы.

Китаплары ак булыр,
Һәр эшендә сак булыр,
Үзен начар күрсәтүдән
Һәрвакыт ерак булыр.

Шәфкать итәр кечегә,
Юл куяр зур кешегә;
Моның кебек баланы
Яратмас кеше нигә!

*Мәҗит Гафури.*

?!

1. Шигырьдә яхшы баланың нинди сыйфатлары бирелә?

#Аклану

“Болай бер эшсез
Өйдә ятканчы ,
Әнием арып,
Эштән кайтканчы,
Бик тәмле ашлар
Пешереп куйгач,
Сулар китереп,
Идәнне югач,-
Бөтен өй эче нурланыр иде,-
Дип уйлый Сәфәр,-
Кыз булсам әгәр”.